КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 6 февраль г.Казань № 74

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә «Чирмешән» комплекслы юнәлешле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигый тыюлыгын оештыру турында»

«Аеруча саклана торган табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Су кодексы һәм Татарстан Республикасы Экология Кодексы нигезендә, биологик төрлелекне саклау, әйләнә-тирә мохиткә хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең тискәре йогынтысын булдырмау, Нурлат муниципаль районында уникаль ландшафт комплексларын саклау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитетының Нурлат муниципаль районы территориясендә гомуми мәйданы 2 344 гектар булган «Чирмешән» комплекслы юнәлешле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигый тыюлыгын оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

«Чирмешән» комплекслы юнәлешле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигый тыюлыгын турында нигездәмәне;

«Чирмешән» комплекслы юнәлешле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигый тыюлыгы чикләрен.

3. «Чирмешән» комплекслы юнәлешле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать тыюлыгы режимының чикләре һәм үзенчәлекләре икътисади һәм социаль үсеш планнары һәм перспективаларын эшләгәндә, территориаль планлаштыру документларын әзерләгәндә, җирләрне инвентаризацияләгәндә исәпкә алына.

4. Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитетына:

Татарстан Республикасының Махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрына тиешле үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдим итәргә;

билгеләнгән тәртиптә «Чирмешән» комплекслы юнәлешле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать тыюлыгы чикләре турындагы мәгълүматларны «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенеТатарстан Республикасы буенча филиалына бирүне тәэмин итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 6 февраль, 74 нче
карары белән расланды

«Чирмешән» комплекслы юнәлешле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать тыюлыгын оештыру һәм аның чикләре турында
нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Чирмешән» комплекслы юнәлешле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать тыюлыгы (алга таба – тыюлык) уникаль су-сазлык комплексын саклау, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән үсемлекләр һәм хайваннарның су һәм су яны төрләрен саклау максатыннан барлыкка килгән төбәк әһәмиятендәге аеруча саклана торган табигый территория булып тора.

Тыюлык Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан һәм гомуми мәйданы 2 344 гектар тәшкил итә.

1.2. Тыюлык Татарстан Республикасының табигый-тыюлыклар фонды составына керә.

Тыюлык чикләре җирлектә тыюлыкны махсус саклау режимын кыскача тасвирламасы һәм аның чикләре схемасы белән махсус мәгълүмати билгеләр белән билгеләнә.

1.3. Тыюлык Татарстан Республикасының Биология ресурслар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Комитет) карамагында.

Комитет урнашкан урын: Татарстан Республикасы, Казан ш., Кәрим Тинчурин ур., 29 йорт.

## 2. Тыюлык эшчәнлеген оештыру Комитетының төп бурычлары

2.1. Тыюлык эшчәнлеген оештыру Комитетының төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

уникаль су-сазлык комплексын саклау;

Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән үсемлекләр һәм хайваннарның су һәм су яны төрләрен саклау.

## 3. Тыюлык эшчәнлеген оештырганда Комитет функцияләре

3.1. Комитет тыюлык эшчәнлеген оештыру буенча үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге төп фунцияләрне гамәлгә ашыра:

тыюлык территориясендә хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау, яңадан торгызу һәм куллану өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыра;

төбәк әһәмиятендәге аеруча саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм куллану өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыра;

юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм гражданнар тарафыннан тыюлыкны махсус саклау режимының әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән үтәлешен тәэмин итә;

тыюлык территориясендә фәнни-тикшеренү эшләрен уздыруга ярдәм итә;

тыюлык территориясендә экологик агарту һәм танып белү туризмын үстерүне тәэмин итә;

тыюлык территориясендә административ хокук бозуларны профилактикалау буенча чаралар күрә, шул максатларда башка табигать саклау органнары белән хезмәттәшлек итә;

тыюлык территориясендә чикләнгән табигать саклау чараларын кертү һәм юкка чыгару турында законнарда билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертә;

барлык хакимият органнарында, шул исәптән суд органнарында һәм оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә оешмаларда тыюлык мәнфәгатьләрен чагылдыра;

тыюлыкның функциональ эшчәнлеге нәтиҗәләрен яктырту мәсьәләләре буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итә;

үз компетенциясе кысаларында Россия Федерациясе законнары нигезендә бүтән функцияләрне башкара.

## 4. Тыюлыкны махсус саклау режимы

4.1. Тыюлык территориясендә тыюлыкның сакланышын бозуга китерә торган теләсә нинди эшчәнлек тыелган, шул исәптән:

язгы ау, санын җайга салу һәм фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатындагы аудан гайре;

рекреацион эшчәнлекне гамәлгә ашыру (шул исәптән Комитет тарафыннан махсус бирелгән ял итү урыннарын оештыру һәм учаклар ягу);

тыюлык эшчәнлеге белән бәйле булмаган биналар һәм корылмалар, торак һәм хуҗалык объектларын төзү (Степноозерск нефть ятмаларын эксплуатацияләү һәм аларга хезмәт күрсәтү максатыннан гамәлдәге лицензияләр һәм рөхсәтләр нигезендә эшчәнлек алып барудан тыш);

картайган һәм куышланган агачларны юк итү;

яндыра башлау, үсемлекләрне яндыру;

су объектларының яр буе саклау полосалары чикләрендә һәм хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлеге сыйфатында аеруча кыйммәтле булган участокларда тростникны юк итү һәм әзерләү;

ау һәм балыкчылык объектларына кертелмәгән хайваннарны, шулай ук Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән, сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайваннарны, үсемлекләрне һәм гөмбәләрне табу;

ояларны, өннәрне, башка ышык урыннарны юк итү, шулай ук кыргый хайваннарны борчуга китерүче гамәлләр;

агу химикатлары, минераль ашламалар, үсемлекләрне яклауның химик чараларын һәм үсеш стимуляторларын куллану, шулай ук агу химикатлары, минераль ашламалар, тирес һәм ягулык-майлау материаллары урнаштыру һәм складлау;

җитештерү һәм куллану калдыкларын, радиоактив, химик, шартлаткыч, токсинлы, агулаучы һәм агулы матдәләр урнаштыру объектларын төзү;

су объекты ярларында автотранспорт чаралары һәм авыл хуҗалыгы техникасы юу;

уртак кулланылыштагы юллардан тыш автомототранспорт чаралары йөрү һәм туктау, моның өчен махсус каралган урыннардан тыш (тыюлык чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре хуҗалары һәм кулланучылары, шулай ук махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан транспорт чараларын куллану белән бәйле очраклардан тыш);

аншлаглар, шлагбаумнар, стендлар, чик баганалары һәм башка мәгълүмати билгеләр һәм тыюлык территориясендә экологик сукмаклар, төзелмәләр һәм корылмалар җиһазландырылган күрсәткечләр юк итү һәм зыян китерү, агачларда язулар һәм билгеләр төшерү;

Россия Федерациясе Су кодексының 44 статьясындагы 2 һәм 3 пунктларда санап үтелгән су объектларына агынты суларны һәм (яки) дренаж суларны агызу;

бу территориянең экологик кыйммәтен киметүгә яки саклана торган хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы объектларына һәм аларның яшәү тирәлегенә зыян китерә торган табигый комплексның экологик тигезлеген бозуга китерә торган эшчәнлекнең башка төрләре.

4.2. Тыюлык территориясендә Комитет белән килешү буенча рөхсәт ителә:

төзелеш, шәхси торак төзелеше, бакчачылык һәм яшелчәчелек өчен җир кишәрлекләре бирү;

магистраль юллар, торба үткәргечләр, электр тапшыру линияләрен төзү.

4.3. Тыюлык территориясендә рөхсәт ителә:

моның өчен махсус билгеләнгән урыннарда терлек чалу һәм су эчерү;

гамәлдәге законнар нигезендә һәвәскәр һәм спорт балыкчылыгы;

янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм тыюлык территориясенең санитар үзенчәлекләрен саклау өчен кирәкле янгынга каршы, санитар-сәламәтләндерү һәм башка профилактик чаралар үткәрү;

тыюлык территориясендә урнашкан линияле объектларны, бүлеп бирелгән полосаларны һәм юл буе полосаларын капиталь ремонтлау һәм ремонтлау, карап тоту;

тыюлыкны махсус саклау режимы белән тыелмаган дару үләннәрен гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз ихтыяҗлары өчен җыю;

фәнни тикшеренүләр үткәрү, шул исәптән экологик мониторинг максатларында;

экологик туристлыкны үстерү кысаларында рекреацион эшчәнлекне гамәлгә ашыру (шул исәптән Комитет тарафыннан махсус билгеләнгән урыннарда ял итү урыннарын оештыру һәм әлеге учаклар ягу);

Степноозерск нефть ятмалары чикләрендә нефть чыгару объектларын эксплуатацияләү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау;

халыкны хуҗалык-эчә торган су белән тәэмин итү максатларында җир асты суларын геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару, җир асты суларының су алу җайланмалары, шул исәптән кирәкле инфраструктура (су әзерләү станцияләре, сүүткәргечләр, күтәрү станциясе, резервуарлар);

хайваннар дөньясы объектлары санын җайга салу буенча чаралар, шул исәптән ау ресурсларына кертелгән;

тыюлыкны саклау максатларына каршы килми торган, су йөзүче һәм су кошларына зыян китерми торган һәм әлеге табигый комплексның экологик характеристикаларын сакларга һәм булышлык күрсәтергә мөмкинлек бирә торган башка эшчәнлек.

4.4. Тыюлык территориясендә рөхсәт ителгән хуҗалык эшчәнлеге тыюлыкны махсус саклауның билгеләнгән режимы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җитештерү процессларын башкарганда, шулай ук транспорт магистральләрен, торбаүткәргечләрне, элемтә һәм электр тапшыру линияләрен файдаланганда, заказникны һәм җитештерү процессларын тормышка ашырганда, хайваннар дөньясы объектларының үлүен булдырмау таләпләрен раслау турында» 1996 ел, 13 август, 997 нче карары белән расланган Җитештерү процессларын башкарганда, шулай ук транспорт магистральләрен, торбаүткәргечләрне, элемтә һәм электр тапшыру линияләрен файдаланганда, заказникны һәм җитештерү процессларын тормышка ашырганда, хайваннар дөньясы объектларының үлүен булдырмау таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.5. Тыюлык территориясендә линия объектларын реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.